# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына кертемнәрнең 1997 елга иминлек тарифы турында**

1 статья. Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына кертемнәрнең 1997 елга иминлек тарифын хезмәт өчен түләүнең һәрьяклап исәпләнгән суммасына карата, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм хуҗалык итүче башка субъектлар өчен - ике процент күләмендә билгеләргә.

Федераль бюджеттан финансланучы предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр өчен процент Федераль закон нигезендә билгеләнә.

2 статья. Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына иминлек кертемнәрен түләүдән азат итәргә:

- Татарстан Республикасының Ветераннар оешмалары советы, гарипләрнең җәмәгать оешмалары, дини берләшмәләр һәм шушы җәмәгать һәм дини оешмалар милкендә булган, барлык табышларын аларның устав максатларын башкаруга кулланучы предприятиеләр, берләшмәләр һәм учреждениеләр, шулай ук хезмәткәрләренең гомуми санының кимендә 50 процентын гарипләр тәшкил иткән предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр;

- хәрби частьләр, хәрби уку йортлары, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы предприятиеләре һәм оешмалары, Татарстан Республикасының Дәүләт иминлеге комитеты, Татарстан Республикасының Эчке эшләр министрлыгы, аның җинаять өчен җәза бирүне башкару системасы, аларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетларыннан финансланучы хуҗалык исәбендәге төзелмәләрен дә кертеп, бүлекчәләре, гражданнарга һәм оешма-

ларга юридик ярдәм күрсәткән өчен үзләренә керүче акчалардан юридик консультацияләргә түләнүче суммаларыннан Адвокатлар коллегиясе, авторлык бүләкләүләре суммасыннан Акыл милкенең Татарстан агентлыгы;

- авыл хуҗалыгы продукциясен сатудан килгән керемнәрнең чагыштырма күләме керемнәренең гомуми суммасыннан 70 процент һәм аннан да күбрәк тәшкил итсә, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән шөгыльләнүче барлык милек рәвешләрендәге авыл хуҗалыгы предприятиеләре.

3 статья. Әлеге акчаларның үз вакытында һәм тулысынча күчерелүен, аларның нәтиҗәле һәм максатчыл тотылышын тикшереп торуны, Татарстан Республикасының Дәүләт салым инспекциясе, Татарстан Республикасының банк учреждениеләре белән берлектә, Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт комитетына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитетына йөкләргә.

4 статья. Әлеге Законны 1997 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 24 апреле
N 1143